СОВЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Новая, д. 1А, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яңа урам, 1А йорты, Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

# КАРАРЫ

**«01» ноябрь 2024 ел** **№6**

**Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Иске Кишет авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Яңа Кишет авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Иске Кишет авылында Иске Кишет авылы, Г.Сафиуллин урамы, 26а йорты адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2024 елның 13 ноябренә 13 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Иске Кишет авылында Иске Кишет авылы, Г.Сафиуллин урамы, 26а йорты адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2024 елның 13 ноябренә 14 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Иске Кишет авылында Иске Кишет авылы, Г.Сафиуллин урамы, 26а йорты адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2024 елның 14 ноябренә 15 сәгать 00 минутта халык җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1 нче этап: Г.Сафиуллин урамында яшәүчеләр;

2 нче этап: Мостовая урамында яшәүчеләр;
3 нче этап: Дружба   урамында яшәүчеләр.

5. Халык җыенына чыгарылучы  түбәндәге мәсьәләне расларга:
«Сез 2025 елда  Арча муниципаль районы  Яңа Кишет авыл җирлеге Иске Кишет авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган  кешедән, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны  һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыелган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктырту челтәрләрен  ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар,  җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру);
-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау, Иске Кишет авылы Мостовая урамы(күперне ремонлау өчен материаллар алу һәм ремонтлау);
- торак пункт территориясен төзетләндерү (МТЗ 82.1 тракторына прицеплы җиһазлар сатып алуны финанслау (үзбушаткыч тагылма)).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ”                                   “КАРШЫ”

6. Арча муниципаль районы  Яңа Кишет авыл җирлеге  Иске Кишет авылында  гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Яңа Кишет авыл җирлеге  башкарма комитетын билгеләргә.
7. Әлеге карарны халык күп җыела торган урында мәгълүмат стендында ТР, Арча районы, Иске Кишет авылы, Г.Сафиуллин урамы, 26а йорты  адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.
8. Әлеге карар  басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Яңа Кишет авыл җирлеге  башлыгы                    Ф.И.Ахмадуллин